**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.02.2017 Балык Бистәсе штп. № 34п

Татарстан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы турында

«Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2014 елның 2 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законны һәм «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының«Татарстан Республикасында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча республика штабы турында» 2015 елның 18 апрелендәге 702-р номерлы күрсәтмәсен гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең хокук бозуларны профилактикалау комиссиясенең, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең һәм Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссиянең 2015 елның 28 апрелендәге 1 нче утырышы беркетмәсенең 1.6.1 пунктына ярашлы рәвештә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы оештырырга.

2. Расларга:

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы турында нигезләмә;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы составы.

3.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы урынбасары (килештерү буенча) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген үзара

хезмәттәшлек һәм координацияләү өчен җаваплы җирле үзидарә органының вазыйфаи заты булып тора дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының 2017
елның 27 февралендәге № 34 пи
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы турында нигезләмә**

I. Төп нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы (алга таба - район штабы) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү һәм аларның җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы территориаль органнары, эчке эшләр органнары (полиция) һәм башка хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлеге максатларында төзелгән даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

1.2. Район штабы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан төзелә

1.3. Үз эшчәнлегендә район штабы Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына, башка муниципаль хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

II. Район штабының төп бурычлары

2.1. Район штабының төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының халык дружиналары эшчәнлеге турындагы мәгълүматны гомумиләштерү һәм анализлау, аерым халык дружиналары эшчәнлегендә уңай тәҗрибә тарату, Татарстан Республикасында үткәрелә торган укыту семинарларында халык дружиналары командирларының катнашуын оештыру;

б) җәмәгать тәртибен саклау мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләргә кертү

III. Район штабының төп функцияләре

3.1. Район штабының төп функцияләре түбәндәгеләр:

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

халык дружиналарын координацияләү органнары (штаблары) белән үзара хезмәттәшлек, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы халык дружиналары белән җәмәгать тәртибен саклауда эчке эшләр органнарына (полициягә) һәм башка хокук саклау органнарына ярдәм итү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек;

б) җәмәгать тәртибен саклауда эчке эшләр органнарына (полициягә) һәм башка хокук саклау органнарына ярдәм итү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы халык дружиналары эшчәнлеген координацияләүгә бәйле мәсьәләләрне һәм тәкъдимнәрне карау

в) халык дружиналары командирларының һәм аларның урынбасарларының таныклыкларын рәсмиләштерүне, бирүне һәм алмаштыруны тәэмин итү;

г) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында хәбәрсез югалган затлар турында һәркем файдалана алырлык мәгълүмат чараларында, аларны эзләүнең күз алдында тотылган урынында, хәбәрсез югалган затларны эзләү буенча чаралар координаторларының контактта мәгълүматын, хәбәрсез югалган затларны нәтиҗәле эзләү өчен кирәкле башка һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматны урнаштыруны тәэмин итү;

д) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең халык дружиналарын координацияләү органнары (штаблары) белән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә үзара хезмәттәшлек итү

е) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре халык дружиналарын координацияләү органнарыннан (штабларыннан) халык дружиналарының эш нәтиҗәләре турында мәгълүмат соратып алу;

ж) җирле үзидарә органнарына хокук тәртибен ныгыту, халык дружиналары эшен камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертү;

з) үз бурычларын үтәгәндә аерылып торган халык дружиначыларын бүләкләү турында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм хокук саклау органнарына җибәрү

## IV. Район штабы вәкаләтләре

4.1. Район штабы үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре халык дружиналарын координацияләү органнарыннан, халык дружиналарыннан, оешмаларыннан

үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле белешмәләрне соратып алырга;

б) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында дәүләт хакимияте башкарма органнарының территориаль органнары вәкилләрен, җирле үзидарә органнарын, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре халык дружиналарын координацияләү органнарын (штабларын) һәм халык дружиналарын халык дружиналары эшчәнлеге турында фикер алышканда үз утырышларына чакырырга;

в) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында территориаль башкарма хакимият органнарының вазыйфаи затларын һәм белгечләрен, шулай ук халык дружиналарына йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыруда практик ярдәм күрсәтү өчен оешмаларны билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә;

г) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре халык дружиналарын координацияләү органнары (штаблар) эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр җибәрергә.

## V. Район штабы эшчәнлеген оештыру

5.1.Район штабын штаб начальнигы җитәкли, ул аның эшен оештыра.

5.2. Район штабы үз эшчәнлеген әлеге Нигезләмә һәм эш планы нигезендә гамәлгә ашыра. Район штабының эш планы аның әгъзалары тәкъдимнәренә нигезләнеп бер елга төзелә һәм штаб начальнигы тарафыннан раслана.

5.3.Район штабы утырышлары кирәк булган саен, ярты елга бер тапкыр уздырыла.

5.4.Район штабы утырышларын район штабы начальнигы яисә аның йөкләмәсе буенча аның урынбасары үткәрә.

5.5. Район штабы утырышының көн тәртибе район штабы секретаре тарафыннан чираттагы утырышны уздыру көненә кадәр ун көн кала эш планы нигезендә төзелә.

5.6.Район штабы утырышын үткәрү датасын һәм вакытын штаб начальнигы билгели, ул булмаганда - штаб начальнигы урынбасары. Утырышның датасы һәм көн тәртибе турында район штабы әгъзалары чираттагы утырышны уздыру көненә кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча район штабы секретаре тарафыннан хәбәр ителә

5.7. Район штабы секретаре кергән материалларны җыя һәм гомумиләштерә, район штабының карар проектын формалаштыра. Утырышлар уздыру өчен материаллар һәм карар проекты район штабы начальнигына утырыш билгеләнгән датага кадәр өч көн кала тапшырыла.

5.8.Район штабы утырышы, составының кимендә яртысы анда булса, тулы хокуклы дип санала.

5.9. Район штабы начальнигы, аның урынбасары, секретаре һәм район штабы әгъзалары утырышларда шәхсән үзләре катнаша.

5.10.Район штабы карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен утырышта катнашкан әгъзаларының яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Район штабы әгъзаларының тавышлары тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

5.11. Район штабының карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм утырышта рәислек итүче һәм район штабы секретаре тарафыннан имзалана. Район штабы әгъзаларының аерым фикере язмача рәвештә бәян ителә һәм район штабы карарына кушып куела.

5.12.Район штабы документларын җитештерү, саклау һәм алардан файдалану секретарь тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.13. Район штабы эшчәнлеген матди-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының 2017
елның 27 февралендәге № 34 пи
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы составы**

| | |
|---|---|
| Ибраһимов<br>Илнур Галим улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы урынбасары, штаб башлыгы (килешү буенча) |
| Вәлиев<br>Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе штп. башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү штабы башлыгы, штаб башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Фатихов<br>Марсель Рамил улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлегенең җәмәгать тәртибен саклау буенча полиция башлыгы урынбасары, штаб секретаре (килешү буенча) |
| Штаб әгъзалары: | |
| Мәннанов<br>Мансур Гомәр улы | «Балык Бистәсе агротехник техникумы» ДАҺБУ директоры (килешү буенча) |
| Хәбибуллин<br>Ленар Рафаэл улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлегенең УУП һәм ПДН бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Кадыров<br>Динар Габдрафыйк улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгының мобилизация эше буенча ярдәмчесе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппараты һәм Башкарма комитеты халык дружинасы командиры (килешү буенча) |
| Җамалиев<br>Рәсим Бәдертдин улы | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге башлыгы |
| Ненастьев<br>Евгений Александрович | Балык Бистәсе муниципаль районының «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәп) формированиеләре үзәге» МБУ директоры |
| | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең халык дружиналарын координацияләү органнары (штаблар башлыклары) җитәкчеләре (килешү буенча) |